КАБИНЕТ МИНИСТРОВ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 28 август г.Казань № 702

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йорт өчен авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында" 2017 ел, 9 ноябрь, 857 нче карарына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йорт өчен авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында" 2017 ел, 9 ноябрь, 857 нче карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

преамбулада «һәм күпфатирлы йортның авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле» сүзләрен «күпфатирлы йортта, авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле йортта, бакча йортын торак йортка һәм торак йортны бакча йортына" сүзләренә алмаштырырга;

әлеге карар белән расланган Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йорт өчен авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында Татарстан Республикасы торак

фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия турында нигезләмәдә:

1.3 пунктта «һәм күпфатирлы йортның авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле» сүзләрен «күпфатирлы йортта, авария хәлендәге һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиешле йортта, бакча йортын торак йортка һәм торак йортны  бакча йортына" сүзләренә алмаштырырга;

3.7 пунктта «торак урыннарны яллаучылар» сүзеннән соң «, бәяләнгән мөлкәткә карата милекче вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы башкарма хакимият органы, предприятие (учреждение), әгәр бәяләнгән мөлкәт тиешле әйбер хокукында  анықы булса,» сүзләрен өстәргә;

3.12 пунктта «карарның бер нөсхәсе –  мөрәҗәгать итүчегә» сүзләрен «10 көн эчендә карарның бер нөсхәсе мөрәҗәгать итүчегә җибәрелергә тиеш» сүзләренә алмаштырырга;

түбәндәге эчтәлекле 3.13 – 3.14 пунктлар өстәргә:

«3.13. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы икенче абзацында каралган функцияне гамәлгә ашырган очракта, комиссия составында күпфатирлы йортны төзүгә рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы йә күпфатирлы йортны файдалануга тапшыруга рөхсәт бирүне гамәлгә ашыручы вазыйфаи затлар, шулай ук дәүләт күзәтчелеге (контроле) органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар һәм экспертлар булганда, проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләрен әзерләү хокукына билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләр нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләрен әзерләү хокукына һәм (яисә), күрсәтелгән рөхсәтнамәләрне бирү өчен кирәкле документларны әзерләүдә катнашкан Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тиешле күрсәтмә чыгару юлы белән әлеге бәяләүне һәм тикшерүне үткәрү өчен комиссиянең вакытлы составын раслау турында карар кабул итә. Шул ук вакытта мондый комиссия составына әлеге вазыйфаи затлар һәм вәкилләр кертелми.

3.14. Комиссия әлеге Нигезләмәнең 2.2 пунктындагы икенче абзацында каралган функцияне гамәлгә ашырган очракта, комиссия составына мәҗбүри рәвештә проект документларына һәм (яисә) инженерлык эзләнүләре нәтиҗәләренә экспертиза бәяләмәләрен әзерләү хокукына билгеләнгән тәртиптә аттестацияләнгән экспертлар кертелә.»;

Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йорт өчен авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия составын яңа редакциядә бәян итәргә (карарга теркәлгән).

Татарстан Республикасы
Премьер-министры — А.В.Песошин

Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының
2017 ел, 09 ноябрь, 857 нче
карары белән расланды
(Татарстан Республикасы
Министрлар Кабинетының 2019
ел, _______ карары редакциясендә)

Бинаны торак урыны, торак урынын яшәү өчен яраклы (яраксыз) һәм күпфатирлы йорт өчен авария хәлендә һәм сүтелергә яки реконструкцияләнергә тиеш дип тану максатларында Татарстан Республикасы торак фондының торак урыннарын һәм башка торак урыннарны бәяләү һәм тикшерү буенча ведомствоара комиссия составы

| | |
|---|---|
| Песошин Алексей Валерьевич | Татарстан Республикасы Премьер-министры, комиссия рәисе |
| Сибгатуллин Илдар Нурзад улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсе башлыгы, комиссия рәисе урынбасары |
| Фролов Алексей Михайлович | Татарстан Республикасы төзелеш, архитектура һәм торак-коммуналь хуҗалык министрының беренче урынбасары, комиссия рәисе урынбасары |
| Вәлиуллин Марсель Мәгъсүм улы | Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппаратының Төзелеш, транспорт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыгы идарәсенең юл һәм төзелеш комплексларында инвестиция программаларын гамәлгә ашыру бүлеге баш киңәшчесе, комиссия секретаре |

Комиссия әгъзалары:

| | |
|---|---|
| Әльмукова Инна Наил кызы | Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының дәүләт милкеннән файдалану бүлеге башлыгы |
| Крайнов Сергей Аркадьевич | Татарстан Республикасының Дәүләт торак инспекциясе башлыгы |
| Кудряшов Василий Александрович | Татарстан Республикасының Дәүләт төзелешен күзәтү инспекциясе башлыгы |

| | |
|---|---|
| Полюшков Алексей Сергеевич | Татарстан Республикасы Экология һәм табигый байлыклар министрлыгының Экологик күзәтчелек дәүләт инспекциясе башлыгы |
| Трофимова Марина Викторовна | Кулланучылар хокукларын яклау һәм кеше иминлеге өлкәсендә күзәтчелек буенча федераль хезмәтнең Татарстан Республикасы буенча идарәсе җитәкчесе урынбасары (килешү буенча) |
| Трущин Максим Владимирович | Россия Федерациясе Гражданнар оборонасы, гадәттән тыш хәлләр һәм табигый бәла-казалар нәтиҗәләрен бетерү министрлыгының Татарстан Республикасы буенча Баш идарәсенең күзәтчелек эшләре һәм профилактик эшләр идарәсе башлыгы урынбасары - дәүләт янгын күзәтчелеге һәм профилактик эшләр бүлеге башлыгы (килешү буенча) |
| Хәмзина Лена Илдар кызы | «Татарстан Республикасының техник инвентаризацияләү бюросы» акционерлык җәмгыяте генераль директоры (килешү буенча) |
| Хөснетдинов Адель Альберт улы | "Татинвестгражданпроект» дәүләт унитар предприятиесе генераль директоры (килешү буенча). |